| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.06.2024 Казан ш № 456

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 27.06.2024 ел, №456 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Түләүсез юридик ярдәм алу, курорт җыемын түләүдән азат итү, бала кирәк-яракларының бүләк комплектын алу, ташламалы шартларда челтәр оешмасы белән электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме яки ялгыз яшәүче гражданинның кереме күләме турында белешмә бирү турында дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2016 елның 11 июлендәге 397 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509, 15.11.2019 №1032, 03.02.2020 №52, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698, 29.04.2021 №275, 22.06.2021 №438, 13.09.2021 № 656, 14.04.2022 №276, 13.03.2023 №159, 02.11.2023 №858 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Түләүсез юридик ярдәм алу, курорт җыемын түләүдән азат итү, бала кирәк-яракларының бүләк комплектын алу, ташламалы шартларда челтәр оешмасы белән электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме яки ялгыз яшәүче гражданинның кереме күләме турында белешмә бирү турында дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.2 пунктның тугызынчы абзацында «стипендия, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.02.2020 №70, 01.06.2020 №380, 09.10.2020 №718, 04.05.2021 №290, 17.11.2021 №846, 04.04.2022 №254, 08.07.2022 №671, 20.01.2023 №21, 02.11.2023 №858 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки)

балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.2 пунктның дүртенче абзацында «стипендия, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2 пунктның дүртенче абзацында «стипендия, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.3 пунктның дүртенче абзацында «стипендия, матди ярдәм» сүзләрен «ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләү» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 2014 елның 19 ноябрендәге 635 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 31.10.2016 №612, 08.06.2017 №349, 01.06.2018 №426, 18.09.2018 №860, 23.04.2019 №297, 14.11.2019 №1021, 10.02.2020 №84, 08.06.2020 №400, 04.09.2020 №609, 21.05.2021 №331, 01.10.2021 №711, 18.04.2023 №294, 10.01.2024 №3 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урыннарга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидияләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.2 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнарыннан (халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләреннән) түләнә торган эшсезлек буенча пособиене алу һәм аның күләме, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләүләрне алу һәм аның күләме турында»;

егерме беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

3 бүлектә:

3.3.1 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3.4.1 пунктта:

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт хезмәте органнарыннан (халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләреннән) түләнә торган эшсезлек буенча пособиене алу һәм аның күләме, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затларга ай саен өстәмә түләүләрне алу һәм аның күләме турында»;

егерме беренче абзацны үз көчен югалткан дип танырга.